ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

ГЛАВА КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**18 октябрь 2024 ел** **№ 5**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Березовка поселогы, Урманче поселогы торак пунктларында гражданнарның үзара салым чараларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нчы статьяларына, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясына, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставының 24 нче статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) таянып, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Березовка поселогы торак пунктында, Березовка поселогы, Центральная урамы, 8 нче номерлы йорт янындагы адрес буенча 2024 елның 2 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Березовка поселогы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, МХО катнашучылар һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләр:

- халыкның күпләп ял итү урыннарын (паркларны, скверларны, яр буйларын, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (туп белән уеннар өчен киртәләп алынган мәйданчык кору) башкару белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Урманче поселогы торак пунктында, Урманче поселогы, Светлая урамы, балалар бакчасы янындагы адрес буенча 2024 елның 2 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Урманче поселогы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, МХО катнашучылар һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләр:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су алу скважинасы территориясен киртәләү эшләрен) башкару белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Биектау муниципаль районы
Красносельский авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов